**Тема:** Тормышта батырлыкка һәрвакытта урын бар
**Максат:** 1. Батырлык сыйфатларын күзалларга өйрәтү;
2. сөйләм телен үстерү;
3. патриатизм хисләре, туган илгә мәхәббәт хисе тәрбияләү.
**Җиһазлау:** Стенд: “Батыр якташлар”, китап күргәзмәсе.

**Дәрес планы**

1. Актуальләштерү.
   Дежур укучы белән әңгәмә кору.
2. Өйрәнгәннәрне ныгыту.
   - Дәреснең темасы, эпиграфы белән таныштыру.
   - Сорауларга җавап бирү.
   - Батыр якташлар турында сөйләү.
   - М.Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы.
   - Тыныч тормышта эшләнгән батырлык.
   - Мәгүбә Сыртланова батырлыгы.
   - Батырлык турында китаплар, мәкальләр
3. Йомгаклау.
   Батырлык турында белемнәрне йомгаклау.
4. Өй эше: М.Җәлилнең “Батырлык” шигырен укырга.

**Дәрес барышы**

1. – Исәнмесез, укучылар! Утырыгыз!
   Дежур укучы белән әңгәмә кору.
   Сезгә өй эше “Мин батырлыкны ничек аңлыйм” дигән темага әзерләнеп килергә иде. Өй эшләрегезне дәрес дәвамында тикшереп барырбыз.
2. Бүгенге дәреснең темасы: “Тормышта батырлыкка һәрвакытта да урын бар” дип атала. Дәреснең эпиграфы:

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә
Ә моның өчен:
Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,
Әтиеңне- әниеңне
Туган илеңне!
Р.Миңнуллин

Батырлыкка һәркайда урын бар
Укучылар сез ничек уйлыйсыз,
- Нәрсә ул батырлык? (Куркыныч килгәндә куркып калмау, нык тору, үз-үзен кызганмыйча кеше бәхете өчен көрәшү)
- Батырлык эшләү өчен нинди сыйфатлар кирәк? (Укучылар җавабы)

Сез әйткән барлык сыйфатлар бергә җыелганда гына батырлык эшләп була.

- Батырлык эшләүче кешеләрне беләсезме? Алар нинди батырлык эшләгәннәр7 (Якташ геройлар турында сөйлиләр).
- Тагын батырлык эшләүчеләрдән кемнәрне беләсез? (М.Җәлил, А.Алиш һ.б.)

Чыннан да Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк безнең шагыйрьләребез, язучыларыбыз сугышка китә. М.Җәлил, А.Алиш, Н.Баян, Г.Кутуй кебек күренекле шәхесләребез сугыш кырларында мәңгегә ятып калдылар. Алар без матур тормышта яшәсен өчен, дошманга каршы үзләрен аямыйча көрәшкәннәр.

Үзенең исеме белән бөтен дөньяга билгеле булган легендар шагыйрь М.Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы нәрсәдә? (Укучылар сөйли).

Укучылар сугышта катнашкан бабалары турында укыйлар.

Без бу батырларны һәрчак истә тотарга тиеш. Алар алдында баш ияргә кирәк. Менә быел Бөек Җиңүгә 65 ел, ләкин яралар әле һаман төзәлмәгән.

Укучылар, батырлыкны кайберләребез бары тик сугыш вакытында гына тормышка ашырыла торган гамәл дип саный. Батырлыкны тыныч тормыш шартларында да эшләргә мөмкин . Намус белән яшәгән кешенең гомере үзе бер батырлык ул.

- Тыныч тормышта нинди батырлыклар эшләп була? (Укучылар җавабы)
- Тыныч тормышта эшләнгән батырлык белән сугыш кырында эшләнгән батырлык арасында нинди охшаш һәм аермалы яклар күрәсез?
- Батырлык ир- егетләр эше генә дип әйтү дөрес булырмы? (Җаваплар, М Сыртланова батырлыгы турында бер укучы сөйли.)
- Батырлык турында нинди китаплар укыганыгыз, нинди кинофильмнар караганыгыз бар? (Укучылар җавабы).
- Батырлык турында нинди мәкаль- әйтемнәр беләсез?

Укучылар, батырлыкка һәркайда урын бар,- дидек. Хәзер дәресебезне йомгаклап, дәрес башындагы эпиграфны искә төшерик. Р,Миңнуллин әйт кәнчә: батырлыкны бөтен кешедә эшли ала, ләкин моның өчен нәрсә кирәк?

Батырлыкны мин бүген батырлык эшлим, батыр булам дип кенә эшләп булмый. Батырлык эшләр өчен сәләт кирәкми. Батырлык ул- уйламаганда, көтмәгәндә, үзеннән- үзе килеп чыга торган күренеш. Син аны хәтта батырлык дип тә белмәскә мөмкин. Батырлык эшләү өчен башта туган илеңне, җиреңне яратырга, әти- әниеңне хөрмәт итәргә тиешсең.

Батырлык темасы- бүгенге көндә дә актуаль проблема. Хәзер сезгә нәкъ менә батырлык һәм романтик хисләр җитми. Чөнки сез күп вакытыгызны телевизор, компьютер каршында үткәрәсез, үзегезнең физик сәламәтлегегез турында кайгыртмыйсыз. Батырлылык эшләргә сез һәрвакыт әзер булырга тиешсез. Батырлык эшләү өчен рухи һәм физик яктан чыныккан булырга кирәк. Батырлык эшләү өчен кешедә ихтыяр көче булырга тиеш.